СОВЕТ
МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
МӘЛКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**30.09.2019 ел.** **Мәлки авылы** **№ 22**

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мәлки авыл җирлеге
Кыр Буасы торак пунктында
үзара салым кертү мәсьәләсе буенча
гражданнар җыены билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Советына туры китереп, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге карар кабул итте:

1. 2019 елның 01 октябрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Кыр Буасы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Кыр Буасы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:
- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;

б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- су үткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

« РИЗА КАРШЫ »

3. Әлеге карарны Мәлки авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Мәлки авыл җирлеге башлыгы Ф.П.Поляков